ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 Казан ш. № 758-153/кс-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.11.2020 №172-29/кс-2020 карарына үзгәрешләр кертү һәм «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.11.2020 №172-29/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 № 60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, «Энергоресурс» ҖЧҖ тарафыннан ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә һәм эчә торган суга, ташландык су агызуга 2024-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында,Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 05.11.2020 №172-29/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 №578-157/кс-2022 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «һәм ташландык су агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Энергоресурс» ҖЧҖ) өчен эчә торган суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 пунктта «һәм ташландык су агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Энергоресурс» ҖЧҖ иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.11.2020 № 172-29/кс-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 758-153/ккс-2023
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Энергоресурс» ҖЧҖ өчен эчә торган суга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | |
| 1 | «Энергоресурс» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 29,18 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 30,34 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 30,34 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 32,12 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 35,00** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 35,00 |
| | | 01.07.2024 31.12.2024 кадәр | 38,98 |
| | | 01.01.2025 башлап | 38,98 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 30.06.2025 кадәр | |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 44,51 |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәлгән хак бәясен исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 24,32 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 25,28 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 25,28 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 26,77 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 29,17** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 29,17 |
| | | 01.07.2024 31.12.2024 кадәр | 32,48 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 32,48 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 37,09 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 №578-157/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге